**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2557**
**20.05.2022**

«2022 елның иң яхшы дворнигы»
исеменә шәһәр конкурсы үткәрү турында

Торак-коммуналь хуҗалыгы һөнәрләренең абруен күтәрү, шәһәрне төзекләндерүне һәм йорт яны территорияләрен карап тотуны яхшырту максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2022 елның иң яхшы дворнигы» исеменә шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) 2022 елның 1 июненнән 2022 елның 16 августына кадәр үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) шәһәр конкурс комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Идарә оешмаларына, торак милекчеләре ширкәтләренә «2022 елның иң яхшы дворнигы» исеменә шәһәр конкурсын оештыруда һәм үткәрүдә актив катнашуны һәм ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 20 маендагы
2557 номерлы карарына
1 нче кушымта

«2022 елның иң яхшы дворнигы» исеменә шәһәр конкурсы үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «2022 елның иң яхшы дворнигы» исеменә шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрүнең максаты булып торак-коммуналь хуҗалыгы һөнәрләренең абруен күтәрү, шәһәрне төзекләндерүне яхшырту һәм йорт яны территорияләрен тиешенчә карап тоту, һөнәр белән кызыксынуга шартлар тудыру, халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итә торган эшләрне вакытында һәм сыйфатлы итеп башкару тора.

2. Конкурсның төп бурычы булып йорт яны территорияләрен вакытында җыештыруга һәм аның сыйфатына таләпчәнлекне арттыру, торак биналарны тышкы төзекләндерү элементларын тиешенчә карап тоту һәм дворникларның торак фондтагы иминлекне тәэмин итү буенча чараларда катнашуы тора.

3. 2010 елга кадәр файдалануга тапшырылган торак фонды белән идарә итүне гамәлгә ашыра торган оешмаларда эшләүче барлык дворниклар да конкурста катнаша ала.

4. Конкурста катнашу өчен кирәкле документлар (күчермәләр):

1) шәхесне раслаучы документ (паспорт);

2) хезмәт кенәгәсе;

3) хезмәт килешүе;

4) торак оешмасы җитәкчесенең хезмәт күрсәтелә торган күп фатирлы йортларны беркетү турындагы приказы.

5. Конкурста катнашуга заявкалар язма рәвештә кабул ителә.

6. Заявкада түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), эш стажы;

2) катнашучы эшли торган оешманың исеме, почта адресы, җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, телефоны.

7. Конкурс материаллары кире кайтарылмый.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

8. Конкурс ике этапта үткәрелә:

1) район этабы – шәһәрнең тиешле район территорияләрендә җиңүчеләрне билгеләү;

2) шәһәр этабы – конкурсның район этабында җиңгән катнашучылар арасыннан җиңүчеләрне билгеләү.

9. Конкурсның район этабы 2022 елның 1 июненнән 2022 елның 18 июленә кадәр үткәрелә.

10. Конкурсның район этабын оештыру һәм үткәрү өчен Башкарма комитетның район хакимиятләре Башлыклары тарафыннан конкурсның район этабын үткәрү буенча конкурс комиссияләре (алга таба – район конкурс комиссияләре) төзелә.

11. Район конкурс комиссияләре түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсның потенциаль катнашучыларына конкурсның район этабын үткәрү турында хәбәр итә;

2) 2022 елның 1 июненнән 2022 елның 13 июненә кадәр конкурста катнашуга заявкаларны кабул итә;

3) әлеге нигезләмәнең 16 пунктында күрсәтелгән бәяләү критерийлары нигезендә, конкурста катнашуга заявка биргән катнашучыларны бәяли;

4) конкурсның район этабына йомгак ясый һәм конкурсның шәһәр этабында катнашу өчен өч җиңүчене сайлап ала;

5) массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту өчен, конкурсның район этабын үткәрү һәм аның йомгаклары турында мәгълүмат бирә;

6) 2022 елның 20 июленнән соңга калмый, конкурс документларын составы Башкарма комитет карары белән раслана торган шәһәр конкурс комиссиясе рәисенә тапшыра.

12. Конкурсның район этабының йомгаклары комиссиянең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштелә.

13. Конкурсның шәһәр этабы 2022 елның 26 июленнән 2022 елның 16 августына кадәр үткәрелә.

14. Шәһәр конкурс комиссиясе түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) әлеге нигезләмәнең 16 пунктында күрсәтелгән бәяләү критерийлары нигезендә, конкурсның район этабында катнашкан җиңүчеләрне бәяли;

2) әлеге нигезләмәнең 3 бүлеге нигезендә конкурсның шәһәр этабына йомгак ясый;

3) массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту өчен, конкурсның шәһәр этабын үткәрү һәм аның йомгаклары турында мәгълүмат бирә;

4) конкурс материалларының саклануын тәэмин итә.

15. Конкурсны үткәрү чорында район конкурс комиссияләре һәм шәһәр конкурс комиссиясе урынга барып йорт яны территорияләрен карый, башлангыч нәтиҗәләрне сыйфат критерийларын бәяләү журналына теркәп куя.

16. Конкурста катнашучылар район конкурс комиссияләре һәм шәһәр конкурс комиссиясе тарафыннан түбәндәге бәяләү критерийлары буенча ун баллы системада бәяләнә:

1) чүп өчен урналарны, контейнерларны, ишегалдындагы чүп җыйгычларны һәм аларны урнаштыру урыннарын вакытында җыештыру, санитар эшкәртү һәм аларның техник торышы – 1 дән 10 баллга кадәр;

2) балалар, спорт мәйданчыкларын, кече архитектура формаларын тиешле тәртиптә тоту – 1 дән 10 баллга кадәр;

3) газоннарны вакытында чабу, яфраклардан, ботаклардан, очраклы чүптән чистарту – 1 дән 10 баллга кадәр;

4) һава температурасы +25°С тән югары булганда, территорияләргә һәм газоннарга су сибү – 1 дән 10 баллга кадәр;

5) подъездның санитар торышы – 1 дән 10 баллга кадәр;

6) подъездларда фатир номерлары күрсәтелгән табличкалар булу – 1 дән 10 баллга кадәр;

7) инвентарь һәм кече механизация чаралары белән тәэмин ителеш – 1 дән 10 баллга кадәр.

Кирәкле инвентарьның нинди дә булса төре булмау билгене 5 баллга киметә; мөстәкыйль әзерләнгән яки сатып алынган теләсә нинди төрдәге җайланмалар, инвентарьның һәм кече механизация чараларының үзенчәлекле үрнәкләре булу билгене 10 баллга арттыра.

8) дворникның пөхтә тышкы кыяфәте – 1 дән 10 баллга кадәр;

9) дворникның вазыйфаи инструкциясе булу һәм вазыйфаи бурычларын бик яхшы белү – 1 дән 10 баллга кадәр.

Вазыйфаи инструкция булмау билгене 10 баллга киметә; вазыйфаи бурычларны канәгатьләнерлек кенә белү билгене 2 баллга киметә; вазыйфаи бурычларны белмәү билгене 5 баллга киметә.

10) дворникка беркетелгән территория буенча Башкарма комитетка халыктан шикаятьләр булмау – 1 дән 10 баллга кадәр.

Халыкның тискәре фикерләре билгене 10 баллга киметә.

Конкурс үткәрү чорында башкарыла торган эш төрләре буенча кимчелекләрнең һәр теркәлгән очрагы өчен билге 10 баллга кими.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

17. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча, шәһәр конкурс комиссиясе тарафыннан конкурсның беренче, икенче һәм өченче урыннарын бирү турында карар кабул ителә.

18. Шәһәр конкурс комиссиясенең карары конкурсның һәр катнашучысына карата ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш буенча кабул ителә һәм 2022 елның 16 августында комиссиянең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Шәһәр конкурс комиссиясенең фактта катнашучы әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

19. Шәһәр конкурс комиссиясенең карары 2022 елның 17 августына кадәр кабул ителә һәм 2022 елның 12 сентябренә кадәр массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

20. Конкурста максималь баллар саны – 100 балл җыйган катнашучы конкурсның җиңүчесе була, аңа «2022 елның иң яхшы дворнигы» исеме бирелә.

21. Конкурс нәтиҗәләре 2022 елның 30 августында үткәрелә торган шәһәр чәчәкләр фестивалендә игълан ителә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 20 маендагы
2557 номерлы карарына
2 нче кушымта

Шәһәр конкурс комиссиясе
составы

| №<br>т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Салахов<br>Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Гайнуллин<br>Илдар Наил улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | | |
| 3. | Альменеева<br>Эльвира Емельяновна | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм шәһәрне төзекләндерү бүлеге башлыгы |
| 4. | Тарабукин<br>Алексей Сергеевич | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| 5. | Хәбибуллин<br>Фидәрис Фәндәвис улы | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| 6. | Харисов<br>Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы. |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева